КЕМ ЭШЛӘР?

Хөкүмәт йортында «Мәдәният» проекты хәл итәсе проблемалар хакында сөйләштеләр

> 2

ИНГЛИЗ АТЛАРЫ

Арча районының Яңасала авылында бахбайларга «педикюр» да ясыйлар

> 3

СУ БАСМАСМЫ?

«ВТ» хәбәрчесе күп еллар язгы ташу нәтиҗәләре белән көрәшүче кешеләрнең хәлләрен белеште

> 3

ХА-ХА-ХАНӘ

Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр биредә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 38 (29198) | Чәршәмбе | 27 март | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТОТЫЛМЫЙЧА КОТЫРУ

Актуаль тема

Быел 1 марттан йорт хайваннарын һава суларга алып чыгуның яңа кагыйдәләре кертелде. Шулай итеп, хәзер дүрт аяклы дусларны хуҗаларына бары тик муенчак һәм борынчык белән генә урамга алып чыгарга рөхсәт ителә. Моннан тыш, этләрне күпфатирлы йортларда тотар өчен, анда яшәүчеләрнең язмача рөхсәтен алырга да туры киләчәк.

– Язын иң яратмаган күренеш – кар эреп, аның астыннан чыккан эт тизәкләре. Моның өчен хуҗаларын берәр нинди җаваплылыкка тартып булмый микән соң? – ди Казанда яшәүче Галия Ибраһимова. – Күршеләребез зур эт асрый. Дөресен әйткәндә, аның өргән тавышлары да, исләре дә, кинәт лифттан килеп чыгып, өскә ташлана язулары да арытты. Инде әйтә-әйтә дә туйдым. Хуҗалары: «Анда сезнең эшегез булмасын», – дип кенә җаваплыйлар. Үзләренә рәхәттер дә, тик аннан без җәфаланырга тиеш түгел бит инде.

Кызганыч, Казан ветеринария берләшмәсенең дәвалау-профилактика буенча баш ветеринария табибы Айрат Хәнәфиев әлегә Галия апаны сөендерерлек сүз әйтә алмады, тик киләчәктә этләре иректә йөргән хуҗаларга штраф та салыначак, йөртер өчен махсус урыннар да булачак, дип ышандырды.

– Әгәр син җан иясен сатып алгансың икән, аның өчен җаваплылык та алырга тиешсең. Шуңа күрә йорт хайваннарына вакытында прививкалар ясатырга, дәваларга, бөтен таләпләрне үтәп, һава суларга алып чыгарга кирәк. 1 марттан ирекле йөртү дигән тәртип бетте. Мондый очраклар күзгә чалына икән, полиция чаралар күрергә тиеш. Күп вакыт этләр балалар мәйданчыкларында йөреп, үз эшләрен башкара. Ә бу – авыру тарату өчен бер сәбәп. Йогышлы авырулар арасында иң яманы – котыру авыруы. Шуңа күрә моны аеруча зур контрольдә тотабыз, мөрәҗәгатьләр килүгә, чаралар күрәбез, – диде ул.

Белгеч әйтүенчә, әлеге вакытта Татарстан котыру авыруыннан имин булып санала. Тик бу әле иркен суларга мөмкин дигән сүз түгел, чөнки күрше Киров, Чиләбе өлкәләрендә авыру очраклары табылган. Республикада котыру авыруына каршы комплекслы эш

УРАМДА СУКБАЙ ЭТНЕ ОЧРАТСАҢ, ҮЗЕҢНЕ НИЧЕК ТОТАРГА?

Каршыга эт килеп чыкса, башыгызны бераз читкәрәк борыгыз. Йөгереп китәргә яки каршында кул, таяк болгарга тырышмагыз. Сукбай булмаса да, хуҗасы янында булмаган эткә якын бармагыз, кагылмагыз, сыйпамагыз. Уенчыгын, ризыгын яки сөяген алу турында уйлап та карамагыз. Әгәр эт усаллана башласа, алга таба иелергә, ышанычлы итеп кычкырырга яки аңа таш ыргытырга җыенган төсле кыланырга.

Илдар Мөхәммәтҗанов

алып барыла. Монда халык белән сөйләшү дә, йорт хайваннарын вакцинацияләү дә, төлкеләргә капкыннар кую да, сукбай хайваннар белән эшләү дә керә.

Роспотребнадзор идарәсе китергән рәсми мәгълүматлар буенча, узган ел хастаханәләргә этләрдән зыян күргән 118 кеше мөрәҗәгать иткән. Кешеләргә ташланган этләрнең 50 проценты хуҗасыз.

Билгеле булганча, закон таләпләре буенча, утлы корал белән торак пунктларга 200 метрдан якынрак килергә һәм этләрне ауларга ярамый. Димәк, сукбай этләрдән котылуның башка чарасын эзләргә туры килә. Һәм соңгы елларда аларны эзлиләр дә кебек, тик әлегә нәтиҗәләре генә куандырырлык түгел. Хуҗасыз этләрне аулаган очракта урнаштыру өчен махсус шартлар булырга, алар ветеринария тикшерүе узарга тиеш.

Сукбай этләр шәһәр халкына гына түгел, авылларга да тынгылык бирми.

– Февральдә авылда өер-өер булып йөрүче этләр саны артты. Авылдашларга да берничә тапкыр кисәтү ясарга туры килде, чөнки балалар мәктәптән кайтканда ташлана яздылар. Алар арасында хуҗалылары да, хуҗасызлары да бар иде. Шулкадәрле этнең каян килеп чыкканын да аңламый калдык. Авыл советына шалтыратып, эт аулаучыларны чакыргач кына, урамга балаларны тынычлап чыгара башладык, – ди Азнакай районында яшәүче Ләйсәнә Абдуллина.

Айрат Хәнәфиев әйтүенчә, узган ел һәм быелның ике аенда сукбай этләрне аулау буенча мөрәҗәгатьләр кимегән. Узган ел башкалада 3,5 мең сукбай этне аулаганнар. Аларның 274е яңа хуҗаларын тапкан.

– Узган ел нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгатьләр саны – 32, тешләү очраклары 18 процентка кимеде. Быелның ике аенда 689 эт ауланган. Аларның барысына да прививкалар ясалды һәм стерильләштерелде. Гыйнвар – февральдә унсигез кеше эт тешләүдән зарланып мөрәҗәгать итте. Узган елның шушы чорында мондый мөрәҗәгатьләр 28 иде, – диде белгеч.

Аның сүзләренчә, хәзер, ягъни язын этләрнең иң агрессив вакыты. Ул тешләү очракларының язын артуын да шуңа бәйләп аңлатты.

– Этләрне аулагач, вакцина ясагач, стерильләштереп, тамга салып, егерме көннән соң кабат үз урыннарына җибәрәләр. Кагыйдә буларак, мондый этләрдә агрессия сизелмәскә тиеш. Кешеләргә исә күп очракларда тамга сугылмаган сукбай хайваннар ташлана, – дип аңлатты ул.

Белеп торыгыз!

Сукбай этләр турындагы мөрәҗәгатьләрне «Ачык Татарстан» һәм «Ачык Казан» сайтларына, «Халык контроле» мәгълүмат системасына, казанлылар шәһәр мэриясенә яки башкаланың Торак-коммуналь хуҗалык комитетына (Кремль урамы, 11 нче йорт, gkh.kzn@tatar.ru) электрон вариантта яки язма рәвештә юлларга мөмкин.

Бурычлар билгеле

Татарстан Министрлар Кабинеты 2024 елга өстенлекле бурычлар исемлеген булдырды. Бу җәһәттән карарны Премьер-министр Алексей Песошин имзалады.

Хөкүмәт мондый бурычлар исемлеген һәр ел саен раслый. Ул алдагы елда уздырылган социологик тикшеренүләр нәтиҗәләренә нигезләнеп төзелә. Шулай итеп, 2024 елга төзелгән исемлеккә дүрт бурыч: бәяләр һәм тарифлар үсүне тоткарлау (республикада яшәүчеләрнең 54 проценты шуны өстенлекле бурыч буларак күрсәткән), эчкечелеккә һәм наркоманиягә каршы көрәш (37,8%), ришвәтчелеккә һәм коррупциягә каршы көрәш (34,9%), әйләнә-тирә мохитне саклау һәм яхшырту (32,7%) кергән.

Карар нигезендә, республика хакимияте органнары бурычларны гамәлгә ашыру чараларын Татарстанның дәүләт программаларына кертергә тиеш. Аерым боерык белән бурычларны үтәүне күзәтү өчен җаваплы кешеләр билгеләнәчәк. Министрлыклар һәм ведомстволар 1 декабрьгә кадәр бурычларны тормышка ашыру буенча башкарылган эшләре турында хисап тотачак.

400 мең түлиләр

Татарстанда Оборона министрлыгы белән контракт төзүчеләргә 400 мең сум күләмендә бер тапкыр түләү 1 апрельгә кадәр озайтылган.

Исегезгә төшерәбез: контракт буенча хәрби хезмәткә алыну өчен паспорт, ә чит ил гражданнарына Россия территориясендә законлы төстә яшәүләрен раслаучы документ булса, шул җитә. Никахлашкан яки балалы кешеләргә никахлашу турында таныклык һәм балаларның туу турында таныклыкларын күрсәтергә кирәк.

Документлар рәсмиләштерү һәм медкомиссия узу бер урында башкарыла. Хәрби хезмәткә яңа кабул ителүчеләрнең һәммәсен тәҗрибәле солдатлар һәм командирлар өйрәтәчәк, ярдәм итәчәк.

Оборона министрлыгы белән контракт төзү өчен, якындагы хәрби комиссариатка яки авыл җирлеге башкарма комитетына мөрәҗәгать итү сорала. Россия Кораллы көчләре сафларында хезмәт итү, шулай ук премияләр, ташламалар һәм түләүләр турында сайтта (https://heroes-tatarstan.ru/) яки 8 (800) 222 59 00, 8 (843) 221 44 52; 8 (843) 299 17 71 телефоннары аша («Батыр» үзәге) танышырга була.

Ял чоры

Язгы каникул чорында Татарстан лагерьларында 17 мең укучы ял итәчәк. Шуның 829ы – мобилизацияләнүчеләрнең балалары.

Яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков әйтүенчә, мәктәп яны һәм шәһәр читендәге лагерьлар эшли башлаган да инде. Быелгы сезонда 280 ял оешмасы балалар һәм үсмерләрне кабул итәчәк.

Министр белдергәнчә, балалар ялының иминлеген тәэмин итү өчен кирәкле барлык чаралар күрелә. «Каникулны үзләренә файдалы итеп үткәрә алачакларына ышанам», – ди ул.

Яңалык

Апрель үзгәрешләре

✓**Социаль пенсия күләме 7,5 процентка арта.** Исегезгә төшерәбез: мондый пенсия, гадәттә, елга бер тапкыр индексацияләнә. Узган елның апрель аенда 3,3 процентка арткан иде.

✓**Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү кәгазендә яңа юл пәйда булачак.** «Узган чорлар өчен яңадан исәпләү» дип атала ул. Күбрәк түләнгән очракта – кире кайтарылачак акча, азрак түләнгәндә – җитми калган акча суммасы күрсәтеләчәк.

✓**Машина йөртүче таныклыгын алу өчен имтихан тапшыруда үзгәреш.** Сынауны 3 тапкыр яки аннан күбрәк бирә алмаучылар аны ярты елдан соң гына кабат тапшыра алачак. Хәзер исә мондый мөмкинлек бер ай узуга ук бирелә. Имтиханның эчтәлеге дә берникадәр үзгәрә. Әйтик, туктау һәм таудан төшәргә җыену осталыгы тикшерелми башлаячак.
Чит илдән килүчеләр өчен дә яңалык бар. Чит илдә бирелгән машина йөртүче таныклыгы (яки халыкара таныклык) Россия паспорты яки илдә яшәү өчен рөхсәт алганнан соң бер ел узгач, гамәлдә түгел дип танылачак.

✓**ОСАГО турында мәгълүматлар алу җиңеләя.** Дәүләт хезмәтләре порталындагы шәхси кабинет аша ОСАГО полисы турында һәм иминиятләштерүгә бәйле башка мәгълүматлар алу мөмкинлеге ачыла.

✓**Тәмәке әйләнешенә контроль арта.** Апрельдән тәмәке һәм никотинлы продукция әйләнешенә дәүләт контроле көчәйтелә. Аларны җитештерүдә яки әйләнештә йөртүдә законнарны үтәмәгән өчен административ җаваплылык билгеләнәчәк. Моннан тыш ваклап сатудагы никотинлы продукция тикшерелә башлаячак.

✓**Микрофинанс оешмалары ачыграк һәм аңлаешлыракка әйләнә.** Мондый оешмалар үзләренең сайтларындагы төп биттә күбрәк мәгълүмат урнаштыра башларга тиеш булачак.

✓**Торак кодексына һәм «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында закон»га үзгәрешләр үз көченә керә.** Шулай ук фатирда бүлмәләргә «перепланировка» ясау тәртибе берникадәр яңартыла. Шул рәвешле торак бинаны торак булмаган бина категориясенә күчерү эше җиңеләячәк.

✓**Мәҗбүри маркировкаланырга тиешле товарлар исемлеге киңәйтелә.** Документ нигезендә, эшмәкәрләргә азык-төлеккә генә түгел, бәлки әле киемсалымга, урын-җир кирәк-ярагына, кайбер башка товарларга да быел 30 сентябрьдән 1 ноябрьгә кадәр маркировка кодларын алып, әйләнешкә кертергә кирәк булачак. Сатып алучыларга продукциянең чынлыгын тикшерү мөмкинлеген бирәчәк бу.

✓**Туристлар өчен үзгәрешләр.** Россиядә яшәүчеләр Болгариянең Мәскәүдәге һәм Санкт-Петербургтагы илчелекләре аша Шенген визасы алу мөмкинлегенә ирешәчәк. Ә инде Санкт-Петербургка килүче туристлар өчен курорт җыемы кертелә. Ул тәүлегенә 100 сум тәшкил итәчәк. Җыем кунакханәләрдә түләтелә.

Сүзгә-сүз

2024 гаилә елы

Камил СӘМИГУЛЛИН, Татарстан Диния нәзарәте мөфтие:

Бәхетле гаилә – җирдә җәннәтнең чагылышы. Гаиләдә җаваплылык тойгысы, балаларны тәрбияләү кирәклеге кешене хезмәт итәргә һәм үз бурычын үтәргә этәрә. Бу юнәлештә дәүләт һәм дини оешмалар бергәләп эшләсә, нәтиҗәсе дә артыр.

РОССИЯДӘ – ГАЛИМНӘР

2017 ел >> **103,3 мең** кеше
77,3 мең >> фән кандидатлары
26,1 мең >> фән докторлары

2022 ел >> **95,2 мең** кеше
71,9 мең >> фән кандидатлары
23,3 мең >> фән докторлары

Росстат мәгълүматлары буенча

Бездә арзанрак

Февраль ае йомгаклары буенча Татарстанда инфляция күләме 7,42% тәшкил иткән. Бу күрсәткеч Идел буе федераль округындагыга (7,54%) һәм тулаем Россиядәгегә (7,69%) караганда кимрәк.

Статистикага караганда, узган айда республикада азык-төлек бәясе, узган елның февралендәге белән чагыштырганда, 8,23 процентка арткан.

Үзәк банк мәгълүматлары буенча, ел башында чит илләрдән банан һәм әфлисун күбрәк кертелгән. Шуңа күрә февральдә бу җимешләр гыйнвар аендагыга караганда акрынрак кыйммәтләнгән. Илебездәге теплицаларда яшелчә күбрәк үстерә башлау да узган айда республикада кыяр-помидор хакының гыйнвар аендагыга караганда азрак үсүенә китергән.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

СЕНЕГАЛ: РОССИЯ ТАРАФДАРЫМЫ, ФРАНЦУЗЛАРНЫКЫМЫ?

Глобаль кризис көчәю фонында дәүләтләр сәяси һәм икътисадый йогынты өчен көрәш алып бара. Көрәшнең асылы аңлаешлы: син йогынтыга ия икән, базар синеке. Соңгы бер-ике елда табигый байлыкларга аеруча бай Африка йогынты өчен чыпчын көрәш мәйданына әверелде. Күбесенчә Франциягә һәм башка Көнбатыш державаларына бәйлелектә торган кара континент илләре, үз хәлләреннән риза булмыйча, глобаль финанс элиталары канаты астыннан чыгарга омтылышны көчәйтте. Бу гаҗәп түгел, чөнки зур табигый байлыкларны Көнбатышка чүп бәясенә генә сатып, процентлы кредитлар кабаласына төшеп яшәгән дистәләгән ил коточкыч фәкыйрьлектә. Күп илләрнең хәтта үз валюталары да юк, французлар баскан акчага сәүдә итәләр. Хәлләрнең мондый торышы протест тудырмый кала алмый. Көнбатышка хезмәт итүче элиталар күп вакыт кораллы фетнә ярдәмендә бәреп төшерелә, кайвакыт оппозиция, сайлауда җиңеп, хакимлеккә килә. Һәм илдән француз гаскәрләре куыла, дипломатларга кайтып китү юлы күрсәтелә. Американнар алдында да ишекләр шап итеп ябыла. 17 март көнне генә, мәсәлән, Нигер хөкүмәте Америка гаскәрләрен илдән чыгаруны таләп иткән рәсми коммюнике игълан итте. Нигерда американнарның зур хәрби һава базасы бар иде.

Үткән атнада көнбатышлылар күзләрен Сенегалга төбәде. 18 миллионлап кеше яши торган бу Африка илендә Президент сайлавы үтте. Ил Африкадагы француз йогынтысының төп (соңгы дип әйтсәк тә була) ныгытмаларыннан берсе иде. Париж шуңа күрә оппозиция тарафдарларының кайсы булса да җиңүен теләмәде. Оппозицион сәясәтче Усман Сонконың ил төбәкләрендә йогынтысы көчле иде, әмма Россия яклы булып исәпләнүче ул кандидатны сайлауга катнаштырмадылар. Тавыш бирүгә ике атна калгач, ул үз партиясендәге икенче кеше – Бассиру Диомайе Файега тавыш бирергә чакырды. Файе үткән язда кулга алынып төрмәгә утыртылган иде. Ләкин амнистия турында канун кабул иттеләр дә, ул, тоткынлыктан чыгып, 19 кандидат арасында сайлауда катнашты.

24 март көнне үткән сайлау нәтиҗәләре әле рәсми рәвештә игълан ителмәде, әмма Файеның җиңүе ышанычлы һәм тарафдарлары тантана итә. Аның төп көндәше Амаду Ба үзенең җиңелүен таныды, Файены беренче турда җиңү белән котлады. Көрәшнең нечкәлекләренә тукталырга урын аз. Шуны искәртик: сайлау нәтиҗәсе илдәге генә түгел, Африкадагы француз йогынтысының җимерелүе дип санала. Макронның ни өчен Россия тарафына нәгърә оруы һәм Украинага француз гаскәрләрен җибәрергә җыенуы аңлашыла торгандыр дип уйлыйм.

Россиядә

НИЧЕК ИШӘЙТЕРГӘ СИНЕ, ЙОМЫРКА?

Глобаль сәясәт уеннарына уңышлы катнашкан Россия санкцияләргә дә яхшы гына каршы тора кебек. Тыюларның ил икътисадын җимермәүләре белән үзебезнең пропаганда да мактана, Көнбатышта да тану бар. Әмма көрәш кискенлеге үзенең югары орбитасына омтылуын дәвам иттерә. Санкцияләр икенчел санкцияләр белән ныгытыла, озакка сузылган перспективада Россия икътисадының акрын гына булса да түбәнгә тәгәрәвенә исәп тоталар.

Россия сәнәгатенең үсеше өч нәрсә белән ныгытыла: нефтькә бәяләр югары тора, хәрби сәнәгать комплексы үткән ел гадәттән тыш үсеш күрсәтте һәм үз артыннан гражданлык тармакларын да ияртте, төзелеш тармагы рекордлы адым ясады. 2023 елда ил тарихында абсолют югары нәтиҗәгә ирешелде: 110,4 миллион квадрат метр торак төзелде. Быел бу потенциал булмас, диләр. Тышкы базарда кара алтын бәясе үсәр, бәлки, әмма Россия үз нефтенә дисконтны арттырырга мәҗбүр. Хәтерлик әле: көнбатышлылар нефтькә түшәм бәя куйгач, Кремль дә ат йөреше ясады. Нефть компанияләренә җир маена бәяне тышкы базар бәясеннән 15 доллардан да түбән куеп сату тыелды. Баррель 75 доллар торганда, 15 долларлык дисконт көнбатышлылар түшәме белән Кремль куйган бәяне тәңгәлләштерә диярлек иде. Аерым очракларда гына кайбер сортларны кыйммәткәрәк озатып булды. Хәзер Мәскәү дисконтның чиген киңәйтте: 20 долларга җиткерде. Димәк, кара алтын бәясе үсәргә мөмкин, әмма Россия өчен зур дивидендлар бирмәс.

Торак төзелешенең рекордлы темпларын саклау да кыенлаша. Төзелеш министрлыгы темпны үстерергә омтыла, әмма Үзәк банк каршы төшә: ипотеканы чикләргә тырыша. Финансчылар позициясе аңлаешлы: бүген каты чабып, иртәгә сулыш кабып туктавың һәм Кытай хәлендә калуың ихтимал. Болай үзе Путинның 2030 елга торак төзелешен 120 миллион квадрат метрга җиткерергә дигән указы бар барын.

Без инде үтеп китте дип санаган йомырка кризисы да беркая китмәгән. Дөрес, бәяләр берникадәр төште, әмма үткән елның шул чоры белән чагыштырганда күпкә югары. Иң мөһиме: илдә инде 6 ай рәттән йомырка җитештерү кими. Быелгы гыйнвар – февраль нәтиҗәләре 1,8 процентка кимү күрсәтә. Бу – аз да түгел, күп тә түгел, 6,11 миллиард данә дигән сүз. Кимүне импорт белән капларлык түгел, сан шуңа ишарә итә.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЮККА ТҮГЕЛ

tatarstan.ru

Якын киләчәктә тормышка ашырылачак, дәүләткә акча китерәчәк һәм кешеләрне эшле-ашлы итәчәк инвестицион проектларның гомуми суммасы – 230 млрд сум. Хөкүмәт йортында узган инвестицион совет утырышында 8 яңа проект каралды. Бу нинди проектлар?

Беренче итеп «Аммоний» акционерлык җәмгыятенең аммиак һәм карбамид җитештерү буенча комплексы төзелеше проекты каралды. Сүз уңаеннан, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та аның кызыклы гына түгел, ил өчен стратегик яктан мөһим булуын да ассызыклады. Шуңа да әлеге проектны җентекләп өйрәнергә кушты ул.

> Бик мөһим проект. Без бу хакта күптән фикер алыштык. Безгә ил эчендә газ куллануны арттыру зарур. Бу – зур инвестицион проект. Әлеге мәсьәләне аерым контрольдә тотарга кирәк, – диде Татарстан Рәисе.

Комплексны Менделеевск районында төзү ниятләнә. Анда 500ләп яңа эш урыны булачак. Совет әлеге проектны хуплады.

Хуплау алган тагын берсе – асфальт-бетон заводы төзелешенең җитештерү базасын оештыру проекты. Бу эш Тукай районында алып барылачак. Проект кысасында 35 яңа эш урыны булдырылачак.

«Яшел Үзән» индустриаль паркында эшләүче хезмәткәрләр өчен хостел (тору урыны) булдырырга җыеналар. Барлыгы өч корпус төзү нияте бар.

Рөстәм Миңнеханов бу хостелда яшәүче кешеләр саны һәм инвестицияләр күләме белән кызыксынды.

– Эшчеләр өчен уңайлы шартлар булырга тиеш, – диде Татарстан Рәисе. – Әлбәттә, безгә эшче куллар кирәк. Әмма хезмәткәрләр хостел шартларында гомер буе яши алмый бит. Аларның киләчәген уйларга кирәк.

Җитәкчелек игътибарыннан читтә калмаган тагын бер проект – вандаллык күренешләренә каршы торучы «антиграффити» япма җитештерә торган предприятие булдыру. Аны Чаллыда ачмакчылар. Проект кысасында 15 яңа эш урыны булдырылачак. Саклагыч япманы бина фасадларында, диварларда, агачларда да кулланырга мөмкин, ди. Инвестиция күләме – 116 млн сум.

Биектау һәм Югары Осланда сәнәгать паркларын булдыруга бәйле проектлар да каралды, Ютазыда «Мизгел Кэмп» глэмпингын төзү, Чистайда «Юность» пляжын булдыру турында да сөйләштеләр.

Казан халкы өчен дә яңалык бар. Казансу елгасы янында ресторан төзеячәкләр. Тамак ялгау, күңел ачу өчен яңа урын барлыкка килүдән тыш, ресторан 80 кешне эшле дә итәчәк.

Партия эше

Халык фикерен беләчәкләр

Праймериз сайлаучылар белән элемтәләрне ныгыту, көн кадагындагы проблемаларны тагын бер кат күтәрү, кандидатларны сайлап алганда республикада яшәүчеләр фикеренә таяну өчен кирәк. Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия»нең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин партиянең төбәк бүлеге Политсоветы президиумы утырышында шул хакта белдерде.

Анда җиденче чакырылыш Дәүләт Советына депутатлыкка кандидатлар буенча башлангыч тавыш бирүләрне башлап җибәрү турында карар ителде.

«Бердәм Россия» праймеризларында катнашырга теләүчеләрдән документлар 27 марттан 25 апрельгә кадәр кабул ителә. Партиядән республика парламентына сайланырга җыенучыларның барысы өчен дә кирәк бу. Кандидатлар 20–26 майда рейтинглы тавыш бирү юлы белән сайлап алыначак. 27 майга башлангыч тавыш бирүгә йомгак ясау күздә тотыла. Исегезгә төшерәбез: җиденче чакырылыш Дәүләт Советы депутатларын сайлау быел сентябрь аенда уздырылачак.

Утырышта башлангыч тавыш бирү буенча оештыру комитеты булдырылды. Аңа 17 кеше керә. Ә инде рәисе итеп Дәүләт Советы Секретаре Лилия Маврина сайланды.

Политсовет президиумы утырышында яңа төбәкләрдә яшәүчеләргә ярдәм итү мәсьәләсенә аерым тукталып үтелде. Аерым алганда, кичә Луганск Халык Республикасына «Бердәм Россия»нең төбәк бүлеге җитәкчелегендә җыелган чираттагы гуманитар йөк колоннасы юл тотты.

Бу юлы алты йөк машинасы Татарстан карамагындагы Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләрендә яшәүчеләргә 100 тоннадан артыграк азык-төлек һәм кирәк-ярак алып киләчәк. Аерым алганда, «Нәфис» хәйрия фондыннан көнкүреш химиясе, яшелчә, азык-төлек һәм чиста су җибәрелгән. Моннан тыш мәктәпләр өчен көнкүреш техникасы, спорт кирәк-ярагы, бер социаль объектның канализациясен яңарту өчен детальләр китереләчәк.

Чираттагы гуманитар йөкне җыюда Дәүләт Думасы депутаты Ирек Богуславский, Дәүләт Советы депутаты, «Татагролизинг» генераль директоры Азат Җиһаншин, муниципаль берәмлекләр башлыклары, предприятие җитәкчеләре, гади халык катнашкан. Түбән Камада яшәүчеләр – 1 тонна китап һәм азык-төлек, аксубайлылар – 1,5 тонна кием-салым һәм азык-төлек, Алабугадан 25 мич җибәргәннәр.

Егерме беренче гуманитар колонна инде бу. Махсус хәрби операция башланганнан бирле партиянең төбәк бүлеге Луганск Халык Республикасына барлыгы 143 йөк машинасы (2163 тонна) ярдәм юллаган.

Илкүләм проектлар

ДИВАРНЫҢ ҖАНЫ ЮК

Бинасы да булыр, акчасы да. Кеше кирәк! Хөкүмәт йортындагы «Мәдәният» илкүләм проектына багышланган брифингта бу фикер күп тапкырлар яңгырады. Мәдәният дөньясында заманча шартлар тудыруны кадрлар мәсьәләсе белән бергә карарга кирәклеге дә кабат искә төшерелде.

Мүклибез дә чутлыйбыз

Республикада «Мәдәният» илкүләм проектын гамәлгә ашыруга багышланган очрашуда Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова чыгыш ясады. Әлеге проект кысасында 2023 елда ниләр эшләнгән һәм быелга нинди эшләр ниятләнгән – саннар телендә әнә шуларны сөйләде. Ирада Әюпова сүзләренә караганда, узган ел 13 мәдәният йортында төзекләндерү эшләре башкарылган, сигез авыл мәдәният йорты төзелгән, Түбән Камадагы музыкаль мәктәп һәм дүрт музей яңартылган. Тинчурин театры һәм республиканың биш музее заманча җиһазлар белән баетылды. Болар барысы да «Мәдәни мохит» төбәк проекты кысасында эшләнгән.

– Быел «Мәдәни мохит» төбәк проекты ярдәмендә 14 яңа объект ачарга ниятлибез. Апас һәм Әлки районнарында яңа авыл мәдәният йортлары ачылачак. Шулай ук күп кенә мәдәни объектларда капиталь ремонт эшләре башкарылачак, – дип сөйләде министр. – 2024 елда Тәтеш, Арча, Алабуга районнарындагы өч музей техник яктан җиһазландырылачак. Алабуга, Чүпрәле һәм Кукмара районнарында модельле яңа китапханәләр ачылачак.

Кем эшләр?

Төзек, матур биналарның ишекләрен ачып, брифингта күп тапкырлар яңгыраган темага әйләнеп кайтыйк. Мәдәни мохитне кешеләр, шәхесләр тудыра. Ә ул шәхесләрне ничек тәрбияләргә, үстерергә соң? Ирада Әюпова сөйләвенчә, бу җәһәттән 2023 елда мәдәният өлкәсендә эшләүче 4,5 мең тирәсе белгеч илнең 13 югары уку йортында белемен арттырган. Быел бу бәхет тагын 1218 белгечкә насыйп булачак. Әле бит төрле зур фестивальләр канаты астындагы белем бирү программалары да бар. Бу эшләр барысы да «Иҗади кешеләр» төбәк проекты кысасында уздырыла.

Әйткәнебезчә, Ирада Әюпова ялт итеп торган биналарда да, күпсанлы чараларда да нәкъ менә кешенең роле зур булу турында кат-кат искәртте. Шулай булгач, бәлки безгә шәхесләргә булган игътибар белән ремонт һәм төзү эшләренә бирелә торган игътибар нисбәтен тигезләргә вакыттыр? Авыл мәдәният учакларына кайтып эшләүче яшьләргә бер мәртәбә миллион бирелә дә бит. Әйтик, гомер буе авыл клубында эшләүче мәдәният хезмәткәренең белеме белән беррәттән хезмәт хакы да артамы икән соң?

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

2024 елда Татарстанда узачак зур мәдәни вакыйгаларның кайберләре

НӘРСӘ?	КАЙЧАН?
«Музей маршрутлары» проекты	24–27 апрель
Бөтенроссия китапханә конгрессы	19–24 май
Халыкара «Нәүрүз» театраль белем бирү форумы	27 май – 2 июнь
Бөтенроссия балалар Фольклориадасы	19–23 июнь
«Татарстанның мәдәни башкаласы» проекты	Ел дәвамында

Быел Сабан туйлары кайларда булачак?

Казанда милли бәйрәм – **23 июньдә**, Чаллыда – **15 июньдә**, ә авылларда һәм район үзәкләрендәге **8–9 июньдә** узачак.

Моннан тыш, Ирада Әюпова сөйләвенчә, быел Сочида – Көньяк Сабан туе, Алтай Республикасында – Төрки Сабан туе, Кемерово өлкәсенең Прокопьевск шәһәрендә IV Халыкара Шахтерлар Сабан туе узачак. 2024 елда Бөтенроссия авыл Сабан туе Пермь краендагы Барда районының Барда авылында, ә Федераль Сабан туе Мари Эл Республикасының Йошкар-Ола шәһәрендә узар дип көтелә. Милләттәшләребезне Калининград шәһәрендә узачак Балтыйк Сабан туе һәм Омск шәһәрендә узачак Иртыш Сабан туенда да көтеп калалар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

АВЫЛ БАХБАЙЛАРЫ

ТОКЫМЛЫ АТ ҮРЧЕТҮ СЕРЛӘРЕ

Шөгыль

Мендең дә атландың түгел. Арча районының Яңасала авыл җирлеге башлыгы, инглиз токымлы чабышкылар асраучы Айрат Сафин әнә шулай ди. Сабан туена да ерак калмады. Аның белән ат үрчетү, ярышларга әзерлек турында сөйләштек.

– Атны берничек тә гараждагы мотоцикл, велосипед яки машина белән чагыштырып булмый. Абзардан атланып чыгып китү өчен ярты сәгатьләп вакыт кирәк. Тренировка вакытында тирлиләр. Тир эзе калмаска тиеш. Калган очракта тәнен кырыргa мөмкин. Шуңа күрә яхшылап чистартырга кирәк. Бик вак нәрсәләргә дә игътибар итәсең, – ди Айрат Сафин.

Сафиннар утарында бахбайларның саны унга якын. Барысы да – чиста токымлы инглиз чабышкылары. Алар арасында Макфорда, Мисс Чейл, Оскан Форд, Рубрика Спейс, Алабама, Экзотика, Чибәркәй исемлеләре дә бар. Исем кушу – бик кызык һәм җаваплы эш. Ни өчен дигәндә, шушы исем белән зур җиңү яулыйсылары бар бит. Гадәт буенча, кушамат тайның «әти-әни»ләренең исемнәреннән хәрефләрне кушып ясала.

Кечкенә генә ат заводы дип тә әйтергә мөмкин. Әлеге хуҗалык атчылык буенча Бөтенроссия фәнни-тикшеренү институтында (ВНИИК) теркәлгән. Бу – эшнең башы. Чөнки һәр туган тайга паспорт ясатырга кирәк. Ә моны шушы институтта гына башкаралар. Нәсел айгырлары, бияләре, чабышларга әзерләнүче 2, 3, 4 яшьлек атлары бар. Быел тайлар саны тагын өчкә ишәер, Алла боерса.

> **Яхшы нәселле атларга хуҗалар табылып тора. Россиянең төрле өлкәләреннән, Казахстан, Монголиядән сораучылар күп. Киләчәктә аларның санын тагын да арттырмакчылар. Сүз уңаеннан, яхшы ат булачагы, тугач та, аның нәселеннән, ничә минуттан аякка басуы, имә башлавы, ничек хәрәкәтләнүеннән күренә.**

– Атлар белән кызыксыну кечкенәдән башланды. 12 яшьтә Сабан туенда катнаша идем. Шул вакыттан бирле ат җене кагылган миңа. Алардан башка тормышымны күз алдына да китерә алмыйм. Шәһәрдә яшәсәм, нишләгән булыр идем икән? Уларым да, кызым һәм биш оныгым (барысы да – малайлар) атлар янында кайнашырга ярата. Бәлкем, нәселдән килә торгандыр. Әбинең: «Кечкенә чагында без дә чабыш атлары асрый идек», – дигәнен хәтерлим. Аннары аларның атларын Гражданнар сугышына алып киткәннәр, – ди әңгәмәдәшем.

Элегрәк, улары яшьрәк чакта, Сабан туйларында узган ат чабышларында еш катнашкан ул. Алай гына да түгел, гел призлы урыннар яулаганнар. Алты ел рәттән район ярышында җиңгән чабышкылар Балтач, Питрәч, Яшел Үзән, Киров өлкәсе, Мари Эл Сабан туйларында да сынатмаган. Ә иң зур җиңү – 2 тапкыр Казандагы халыкара ат спорты комплексында уңышка ирешү.

– Иң яхшы биябез Алабама кушаматлы иде. 11 яшендә дә район Сабан туенда беренче килде. Аның тайлары: Сократ (12 апрель – Космонавтика көненда туган) Казан Сабан туенда отты, Экзотика, Санадор, Албәна, Карамелька, Абаль да зур җиңүләр яулады. Барысын да үзебез тәрбияләп үстердек. Ә хәзер бездә туып-үскән атлар башка хуҗаларны сөендерә, – ди Айрат Сафин, атлары белән горурланып.

Аның әйтүенчә, чиста токымлы инглиз чабышкылары белән спортның башка төрләрендә дә катнашып була. Мәсәлән, стипль-чез, конкур, байга (казах). Ләкин аларның билгеләнеше токымның исеменнән үк күренеп тора. Чиста токымлы аргамаклар, юрткалар белән бутарга ярамый. Бу атлар 69 км/сәг тизлек белән чаба ала. Әйтик, 27 секунд эчендә 500 метр ара үтәргә сәләтле. Аларны хуҗалык эшендә кулланып булмый.

Һәркайсының – үз холкы. Аларны кулга ияләндерү туган көннәреннән үк башлана. Кайсыдыр куркак булырга мөмкин, ә кайберләре кулга бик тиз ияләшә, лел сыйпап торганны ярата. Аларга тавыш һәм кул күтәрергә ярамый. Кулга ияләштереп, ышанычын яулау һәм җиңүгә ирешү өчен дә шактый вакыт сорала. Шулай булганда тешләми дә, типми дә алар. Иң нәзберек җире – ашкайнату системасы. Чиста су һәм азык бирергә кирәк. Атлар өчен төрле катнаш азыклар, витаминнар бар. Аларны кулланмыйча гына җиңүләр яуланмый.

Атларга ничек «педикюр» ясаулары белән дә кызыксындык.

– Яшь атның аякларын саклау аның дөрес формалашуына ярдәм итә. Аның тоягын ай саен кисеп, чистартып, ягъни «педикюр» ясап торасың. Бу эшләрне үзебез башкарабыз, ә дагалау өчен белгечләр чакыртабыз, – ди Айрат Сафин.

Тиздән ат чабышлары сезоны якынлаша. Айрат Сафин белдергәнчә, безнең төбәктә чабышкы атлар асрау, аларны чабышка әзерләү бик кыен. Быелгы кышның карлы булуын искә алсак, атчыларга тагын бер кат сабырлык телисе генә кала.

Нигездә, ат асраучылар авылда яши. Шулар аркасында Сабан туе күрке булган ат чабышлары дәвам итә. Егетләрдә бу энтузиазмны бетермәү өчен, Айрат Сафинның республика җитәкчелегенә, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына тәкъдимнәре бар.

– Авыл һәм районнардан килүче ат сөюче дусларыбызга Казан ипподромы ишекләре һәрвакыт ачык һәм бушлай булсын иде. Алар өчен аерым, приз фондлары югары булган ярышларның күбрәк уздырылуын телибез. Кыш буе ипподром шартларында яшәгән яки илнең җылы төбәкләрендә туып-үскән, тренинг үткән атлар белән авыл бахбайларын бер ярышта чаптыру дөрес түгел дип саныйм, – ди ул. – Узган ел Татарстанда туган атлар өчен аерым бер приз булдырылды. Бу ярышта катнашу һәм җиңү өчен, барлык атлар да тырыша. Көндәшлек булырга тиеш, шулай гына үсеш, алга китеш булачак. Ләкин барысы да гадел булсын. Ат яраткан бар кеше дә чиста токымлы атлар асрый алмый. Районнарда ярым чиста токымлы атлар бик күп. Алар өчен аерым ярышлар уздырылсын иде. Менә шул вакытта тамашачылар да булачак. Ат җене кагылган татар агайлары, малайларының өметләре аклансын иде.

Сәрия МИФТАХОВА

«НУР»НЫҢ ҖЫЛЫСЫ ҖИТӘРЛЕК

Яшәеш

Бередә һәркемне елмаеп каршы алалар. Чөнки яхшы мөнәсәбәтнең, бер-береңә булган хөрмәтнең бары тик уңыш һәм бәхет китерәсенә ышаналар. Яшәшдәгеләргә дә шуны аңлатырга тырышалар.



syuyumbike.ru

Сүзем – коммерцияле булмаган «Нур» хатын-кызлар социаль инициативалар ассоциациясе турында. Аның җитәкчесе эшмәкәр, «Сандугач» хәйрия фонды президенты Айгөл Хәйруллина үз янына актив хатын-кызларны җыйган.

– Дөньяга яктылыкны, җылылыкны без – хатын-кызлар гына бирә алабыз. Хатын-кыз – энергия чыганагы. Аны ача белергә генә кирәк. Без һәр гүзәл затны бәхетле итәргә тырышабыз, – ди Айгөл Хәйруллина. – Гомерем буе эшмәкәрлек белән шөгыльләндем. Бервакыт белгәнеңне башкаларга бирәсе килә башлый. Озак та үтмәде, шушы оешманы төзү уе белән яши башладым. Аннары инде аны коммерцияле булмаган оешма итеп теркәдем. Болай эшләгәндә мөмкинлекләр зур. Грантлар отарга, дәүләт оешмалары белән элемтәдә торырга мөмкин.

Айгөл Хәйруллина үзләре канаты астындагы хатын-кызларның үзгәрүенә соклана. Аларның оешмасына төрле проблемалы ханымнар килә икән. Без барган көнне Башкортстан кызы Юлия дә бар иде. Күп еллар Санкт-Петербургта яшәгән. Ике ел элек, ире белән кинәшләшеп, Казанга яшәргә күченгәннәр.

– Күчелебезгә Казан шәһәре бик якын булды. Уйлаштык та күченергә булдык. Әлегә бер кыз үстерәбез, икенче бәбиебезне көтәбез. Иремнең үз эше бар. Казанга күченгәч, мин башта югалып калдым. Аннары танышларым аша бу оешмага килеп әләктем. Мондагылар ярдәме белән бизнес алып барырга өйрәндем. Эшмәкәрләр белән таныштым. Ул чакта дингә килгән идем инде. Аеруча дини яктан да белемле булган хатын-кызлар белән якынайдым, – ди Юлия. – Хәләл ризыклар әзерләү белән шөгыльләнәбез. Заказга күбрәк иртәнге ашлар әзерлибез.

Күп бала әнисе Алсу Насыйбуллина да «Нур» оешмасы көннән-көн бирле бередә. Ул мондагы хатын-кызларны интернетта үз блогыны алып барырга, социаль челтәрләрдә дөрес итеп эшләргә өйрәтә.

– Монда рәхәт. Һәркем белгәне белән бүлешә. Бергәләп ярдәмләшәбез. Хатын-кызлар өчен мондый җылу урыннары бик кирәк, – ди Алсу. – Күпләр өйдән дә чыкмыйча ята. «Син ничек гел йөреп торасың?» – диләр. Йөрергә кирәк. Кая чакырсалар, шунда барыгыз. Кеше арасында бар проблемалар онытыла. Кайчак мәңге бетмәс сыман тоелган борчуларга да бергәләп җавап табабыз.

Айгөл Хәйруллина үзләренә килгән кызларның көннән-көн үзгәрүен әйтә. Аралашу, белгәнең белән бүлешү, ярдәмләшү кебек сыйфатлар әнә шулай яшәү мәгънәсен үзгәртә икән кайчак. Бередә психологик тренинглар, кул эшләре буенча төрле мастер-класслар уза икән. Шулай ук юридик, психологик һәм идарә буенча киңәшләр дә алалар.

– Оешмабыз республиканың социаль тормышында, хәйрия проектларында, төрле күргәзмәләрдә актив катнашып, гаилә кыйммәтләрен саклауга зур өлеш кертә, бизнес-идеяләрне тормышка ашыра. Гаиләләрне саклап калу өчен дә тырышабыз, – ди Айгөл Хәйруллина. – Тормыш мәшәкатьләреннән арыган хатын-кызлар безгә килүгә, бөтенләй ачылып китә. Гаиләдәге мөнәсәбәтләре дә яхшыра. Бар да үзебезнең кулда. Телибез икән, бәхетле да булабыз, бәби дә сөябез, ир белән дә яхшы яшибез. Мин гел әйтәм: әгәр хатын-кыз үз энергиясен дөрес итеп тотса, ул бернинди ЭКОсыз бәби алып кайтыр иде. Үз өстеңдә эшләргә кирәк. Шөкер, оешмабызга йөрүче хатын-кызлар әкренләп үз-үзен яратырга, матур итеп яшәргә өйрәнеп килә. Без моңа бик шат. Димәк, дөрес юлдан атлыйбыз.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сан

«НУР» оешмасының **300** әгъзасы бар. Бирегә йөрүче **160** хатын-кыз үз эшен башлаган. Алар **3** миллион сумга якын **6** грант откканнар. Оешма **8** форум уздырган. **20** хәйрия чарасы үткәрелгән. Оешмага йөрүче **17** хатын-кыз бәби алып кайткан. **53** гаиләне аерылышудан саклап калганнар.

Форум

Кунак көткәндә

Киләсе атнада Татарстан башкаласы энергетика үзәгенә әверeләчәк. 3–5 апрельдә Казанда энергетика һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы узачак.

22 нче тапкыр уздырылучы чарада илнең 16 төбәгеннән һәм федераль дәрәҗәдәге шәһәреннән вәкилләр җыелачак. Моннан тыш Белоруссия, Кыргызстан белән Казахстаннан да кунаклар көтелә.

Татарстан сәүдә һәм сәнәгать министры урынбасары Марат Минебаев сүзләренә караганда, быелгы форумда Кытайдан да вәкилләр катнашыр дип көтелә.

– Быелгы форум технологик бәйсезлек, энергияле машина төзелеше мәсьәләренә багышланачак. Татарстанда узучы халыкара форумга ел саен илнең төрле төбәгеннән, чит илләрдән энергетика тармагы белгечләре килә. Форум барышында тармактагы актуаль мәсьәләләр күтәрелә, – дип ачыклык кертте министр урынбасары.

Быелгы форум программасына барлыгы 30лап чара кертелгән. Алар энергия нәтиҗәлелеген арттыру, энергетика-ягулык комплексы үсеше, альтернатив ягулык төрләре үсеше, энергетика комплексын цифрлаштыру мәсьәләренә багышлана. Форум кысасында «Татарстан Республикасында энергия ресурслары нәтиҗәлелеге» программасын тормышка ашыруга багышланган хөкүмәт утырышы да узачак. Анда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашыр дип көтелә.

Форум көннәрендә «Казан Экспо» күргәзмәләр мәйданчыгында «TatEnergyExpo» махсуслашкан күргәзмәсе дә эшләячәк. Анда энергетика тармагында хезмәт куйган 82 оешма катнашачак. Алар тармак үсешен тәэмин иткән заманча җиһазлар, импорт алыштыру алымнарын тәкъдим итәчәк. Узган ел шушы күргәзмәдә катнашкан оешмаларның 81 проценты яңа хезмәттәшләр, клиентлар тапкан.

Сораштыру

Илдар Мөхәммәтҗанов

Су басудан куркасызмы?

Татарстанның Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе мәгълүматлары буенча, апрель башында һава температурасы көндезге сәгатьләрдә +6, ә кайбер районнарда +9 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнге сәгатьләрдә исә 0...+3 градус булачак. Су басмасмы? «ВТ» хәбәрчесе күп еллар урамнарын су баскан, өйләренә су кергән кешеләр белән сөйләште.

Рәшит ГАПТЕРӘХИМОВ
(Яшел Үзән районының Татар Танае авылы):
– Ел саен безнең урамга су керә иде. Коймәләрдә дә йөргән булды. Узган ел безгә су кермәслек итеп дамба салып куйдылар. Бер яктан, күңел тыныч, икенче яктан, әгәр кар кинәт эресә, су безне катырак басарга мөмкин бит! Әмма гөрләвекләр ага башлагач, тынычландым. Быел ташуга әзерләнмәдек. Бер әйберне дә өскә күтәрмәдек. Умартылар да шул килеш тора, терлекләр дә.

Роза САТТАРОВА
(Кайбыч районының Борындык авылы):
– Февраль ахырында ук өйдәге бөтен әйберне җыя башладык. Быел кар күп бит. Куркыта. Күңелем тыныч түгел. Ике авыру балам да бар. Безгә ел да су керә. Инде йорт түбәләрендәге карларны әкренләп бакча ягына ташладык. Балаларым булыша. Ишегалларын чистартып куйдык. Кирәк-яракны түбәгә күтәрдек. Кайчак су керүне уйлап авырып та китәм. Узенне сүгеп тә ташлыйм. «53 ел бүе торам бит инде, агып киткәнем юк», – дим. Әгәр су күтәрелә башласа, без чыгып китәбез. Ул көнне өйдә йокламыйбыз.

Зөлфия МӨБАРӘКШИНА
(Балтач районының Борнак авылы):
– Әлегә су күренми. Әмма без әзер инде. Бәрәңгеләрне печәнлеккә менгереп куйдык. Төнлә салкын тора бит әле. Шуңа күңел тыныч. Көндез җылытып карны эретсә, төнлә салкынча булса, су басмас, дибез. Быел туң да булмады, кар суы җиргә сеңеп бара. Шулай да һава торышына бик ышанып бетеп булмый. Су өйгә генә кермәсен иде инде, аның дымы озак бетми. Малларыбыз күп түгел, өч үгезебез бар. Аларны биеккәрәк менгереп куйдык.

Нуретдин ШИҺАПОВ
(Мамадыш районының Түбән Яке авылы):
– Быел ташу булмас, дип уйлыйм. Безнең авылда инде тау башлары ачылып бетте. Урамнарда кар күп әле. Өй тирәләрен кардан чистартып, канаулар ясап куйдык. 22 март көнне кара каргалар килде. Кичә сыерчыклар килеп урнашты. Кинәт җылытырга да ашыкмый бит әле. Былтыр мартның 29ында умырзаялар җыеп кайткан идем. Узган ел 14 апрельдә ташу киткән булган. Инде быелгысы ничек булыр, күтәбез. Хәере белән килсен язлар да, җәйләр дә.



ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе



Мач әйткән!

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН, язучы:

– Халыкны ярату җиңел ул, син кешене яратып кара.

Ир – баш...

Өйләнү түгел сөйләнү

Безнең мөнәсәбәтләребез бик җитди: ул мине сториста күрсәтте.

– Бала белән дәрес хәзерләүдән дә авыррак нәрсә бар микән ул дөньяда?
– Хатының белән обой ябыштыру.

Яз җитте! Үлеп гашыйк буласым килә. Әмма хатыным каршы.

– Бернинди кимчелекләреңә карамый яратам, диде ул миңа.
– Ә син?
– Туктале, минем кимчелекләрем болай да юк бит, дип уйлап куйдым.

Ялкаулар бер генә тапкыр өйләнә.

Хатынымнан смс килде. «Алга таба без бергә була алмабыз», – дигән. Бер минуттан соң «Сиңа түгел» дигән смс килгәч кенә тынычландым.

Һәр ир-ат өйләнергә тиеш. Рәхәт яшәүдә генә түгел бит инде тормышның мәгънәсе!

Хатирә

МАНСУР ШИҺАПОВ: «КИЛЕГЕЗ ӘЛЕ, КЫЗЛАР!»

Танылган шагыйрь, популяр җырлар авторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мансур Шиһаповның арабыздан киткәненә бер елдан артык вакыт узды. Әмма аның шаян сүзләрен әле дә җылылык белән искә алабыз. Тормышта хроник оптимист була ул. Көнкүрешкә юмор аша карашы бик күп авырлыкларны җиңәргә ярдәм итә. Мансур абый хатыны Клара апа белән ике кыз үстерделәр. Ата кеше балалары белән гел шаярып-төрттереп сөйләшә торган булган. Берзаман фатирда бер бүлмәдән икенче бүлмәгә Мансур абый кычкыра: «Эльвира! Ләйсән! Килегез әле, кил!» Нәрсә булды икән дип, кызлары йөгереп керә. «Утырыгыз. Хәзер сезгә әниегез белән ничек танышканыбызны сөйлим». «Соң, әти, йөз тапкыр сөйләдең бит инде аны!» – ди кызлары. «Ашыкма әле син. Бу юлы дөресен сөйлим», – ди Мансур абый.



Авыл хәлләре

БЕР КАРТ ҺӘМ АТ



Безнең әти-бабайлар өй-йортка килеп керүгә: «Малларыгыз исән-саумы?» – дигәч кенә хәл-әхвәлләрен белешкәннәр һәм ил-көннәр исәнлегеиминлегенә дога кылганнар. Чөнки гаиләнең муллыкта яшәвен нәкъ шул мал-туар һәм иң әүвәл сөтлебикә – сыер билгеләгән. Әле әнә төнлә күршебезнең никадәр зарыгып көткән акчуар сөтлебикәсе тана бозау китергән, иртәдән бирле янында мәш киләләр, ничек кадерләргә белмиләр. Чын бәйрәм, шатлык-күтәренкелек инде! Күршеләренә дә бик тансык, чөнки хәзер шундый заманда яшибез, мәшәкать чикмичә генә бөтенесен супермаркетлардан төяп кайтырга күнеккәнбез, югыйсә акылы булганнар бер дә химия кушылган ризык белән туклану ягында түгел. Шуңа күрә без – уртача урам-тыкрыкта көн күрүчеләр дә күршебезнең акчуарына карап торабыз – ни дисәң дә, иртә белән яңа сауган йомшак тәмле-җылы сөтле чәй эчү үзе бер бетмәс-төкәнмәс ләззәт инде! Бар иде бит әле кайчан гына һәр өй-йортта сыер тотып, әле кайсыларында икешәр-өчәр баш сөтлебикә асрап, урам чүмәләмә тулы көтү чыккан чаклар. Җирле җитәкчелек тә бу җәһәттән һәрдаим ярдәм итеп, шәхси хуҗалыкларга аерата сыер асрауда кайгыртучанлык юлында торды. Хакимиятләрдә атна саен авыл җирлекләрендә шәхси хуҗалыклардан сөт җыеп тапшыруның барышы буенча катгый киңәшмә уза, урыннарда эшнең яхшы баруына җаваплы билгеләнгән чиновник-вәкилләрнең нәрсә майтарып йөргәннәре тыңлана, оешмаганнарга каты шелтәләргә кадәр белдерелә. Кашыклап сөт җыюны булдырмаган бер-ике чиновникны эшеннән чөйделәр хәтта.

Бу сөт мәсьәләсе «Маяк» газетасының да даими игътибарында. «Бер карт белән ат» дигән язмабыз чыкты. Аны район хуҗасы чираттагы киңәшмәдә, әллә кем-кайберләрне тозлап-борычлап, күтәренке мәкамда тулысынча укып чыкты да: «Ә бит сөтне вакытында җыеп тапшырырга күп тә түгел, бәлкем бер карт белән ат җитә!» – дип, моның өчен журналист халкына чуктин-чук рәхмәтен җиткергән иде. Менә бит, абзаң үтемле язма яза белгәчтен! Әле хәзер, мин әйтәм, күршебездә хотя бы бер сыер бар, ул да бетәргә озак түгелдер мондый чуалчык хәлләрдә, аннары каян күрерсең яңа сауган свежий тәмле-җылы каймак-сөтне һәм кайчан йөрер ул урамыбыз буйлап «Бер карт белән ат» дигән хөкүмәткә дә файда китерүче сөт җыючы игелекле җан ияләре. Ярый ла бүген андый эшне оештырып җәфаланасы түгел, кем әйтмешли – бүре дә тук, сарык та исән!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районының Сәпәй авылы

Сәер юмор

~~Җүләр~~ Акыллы уйлар

! Диңгездән үрнәк алыгыз: бераз дулкынланыгыз да тынычланыгыз.
! Тәнне фитнес-клубта калдырып, әзер булгач кына алып китсәң иде ул.
! Дәшми тормагыз, тормыш болай да бик кыска. Дөрес, дәшсәгез, тагын да кыскарырга мөмкин.
! Хәзерге телефоннарда телефон функциясен кайчан бетерерләр икән? Шулхәтле комачаулый.
! 40 яшьтә будильник куясы юк. Проблемалар сине үзләре уята.
! Көндез йоклап алырга. Өйдән чыкмаска. Аш ашарга. Йокларга иртәрәк ятарга. Балачак җәзалары – олы тормышның бәхетле мизгелләре.
! Әгәр балаңа кайчының кайда икәнен күрсәтеп, аны алмаска кушсаң, кич белән паспортыңны киселгән килеш таба алырсың.
! «Бер-ике сәгатьтән булам» һәм «бер ике сәгатьтән булам» арасында аерма бик зур.



! Минем финанс грамоталыгымны «дөньяда бер генә тапкыр яшибез» дигән фикер чәлпәрәмә китерә.

Әз-мәз мәзәк



Елена Малышеваның оныгы утренникка тромб костюмында килеп, әйлән-бәйләнне туктаткан.

***

– Әти, нәрсә якынрак: аймы, Бөгелмәме?
– Балконга чыгып кара әле, нәрсә күрәсең?
– Айны күрәм.
– Ә Бөгелмәне?
– Бөгелмәне күрмим.
– Димәк, ай якынрак.

***

Су буенда утыручы балыкчы янына полиция хезмәткәре килеп бәйләнә:
– Сезон әле ачылмаган, ә сез инде балык тоткансыз. Моның өчен штраф каралган!
– Ә мин бу балыкны өйдән үзем белән алып килдем. Миндә яши ул. Дрессировкаланган. Атнага бер шулай суда йөздереп алып кайтам.
– Ничек инде?
– Менә суга ыргытам да, бераз йөзгәч, сызгырам һәм ул кире чыга.
– Яле, күрсәт!
Ир-ат балыкны суга ыргыта.
– Йә! Сызгыр! – ди погонлы кеше.
– Нәрсәгә?
– Балыкка!
– Нинди балыкка?

Булмас димә!

ТОРМЫШТА БУЛГАН ХӘЛЛӘР

Аэропортта

Бу хәл илебез аэропортларының берсендә килеп чыга. Башка шәһәрдән килгән пассажир үзенең багажын югалта. Чемоданнар әйләнә торган тасмада үз йөген тапмагач, биредә эшләүче җаваплы кешеләргә мөрәҗәгать итә. «Бер дә борчылмагыз, – ди матур форма кигән ханым, – сезнең чемоданыгызны, һичшиксез, табып бирербез. Безнең бу өлкәдә тәҗрибә бик зур. Эзләү эшләрен башлар өчен беренче сорау: «Сезнең самолетыгыз әле очып килдеме?»

Лифтта

Күп катлы йорт. 1 нче этаж. Лифтка бер егет йөгереп керә. Лифт эчендәге кешеләр моңа сорау бирәләр: «Сезгә ничәнче катка?» «Унтугызынчы», – ди егет. «Безнең йорт 17 катлы гына бит», – ди күршеләр. «Ә, шулаймыни, алайса, мин бармыйм», – ди теге һәм лифттан чыгып китә.

Институтта

Шундый заман, студентлар укытучылар белән телефоннан язышып кына сөйләшә хәзер. Берзаман укытучыдан смс килеп төшә: «Вәлиев! Мин бит сезгә бүген өченче «пара»дан соң китмәскә куштым». Студент җавап яза: «Ә мин өченчедән китмәдем». «Ә, шулаймыни, гафу, алайса, игътибар итмәгәнмендер». Студент, чыннан да, өченче «пара»дан соң түгел, ә беренчедән үк киткән була.

Балалар бакчасында

Балалар бакчасыннан кайткан сабый өйдә ашап утыра: «Әни, ә ник бу ботканың төерләре юк?» Әни кеше аптырап кала. Ботканың төерләре булмагач, әйбәт бит инде. Балага шуны аңлатмакчы була. Тик сабыйның үз сүзе – сүз. Төер кирәк! Бу табышмак соңыннан гына чишелә. Баксаң, бүген балалар бакчасында ботка төерле булган икән. Тәрбияче исә: «Һәр төерне ашаган саен бер хыялыгыз чынга ашачак», – дип, ботканы сабыйларга ашатып бетергән.

Кызык-мызык

ЯШЬ БАРА БИТ, ЕГЕТЛӘР!

– Әни! Ура! Син салган бөтен ризыкны беренче булып ашап бетердем.
– Менә шуңа күрә синең аерым яшәвеңне телибез дә инде.

– Вакыт һәр нәрсәне үз урынына куячак.
– Бүлмә алай җыештырылмый, улым.

Тормыш турында нәрсә беләсең соң син, 90 нчы елларда базарда картон кәгазьгә басып чалбар киеп карамаган кеше!

– Сезнең улыгыз инде шушы яшьтән үк начар сүзләр әйтә.
– Тәпине дә иртә киткән иде ул.

Буегыз 160 сантиметрдан ким булса, зинһар, бүген урамга чыкмагыз – һавада зур бөркет әйләнеп йөри.



Яшь барган саен, туган көн тизрәк килеп җитә.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 2095 данә
Гомуми тираж – 11293 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 235

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+